## Балалар һәм чуртан

Идәнгә яки җиргә (уен мәйданчыкта үткәрелгәндә) сызык сызып, елга урыны билгеләнә. Елгада балыклар (балалар) йөзәләр, әйләнәләр, бер-берсен куалар (сызыктан читк чыкмыйлар). Елганың бер башында таш астына качкан «чуртан» уйнаучы балыкларны күзәтеп тора. Кинәт чуртан, таш астыннан чыгып, балыкларны куа башлый. Балыклар аннан качалар, тотылган балык чуртан ролен үти. Уен кабатлана.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе “4нче номерлы “Ләйсән” гомумүсеш төрендәге балалар бакчасы”

***Уйный***

***Үсәбез***

***Уйный***



## Авыз ачып калма

Балалар түгәрәк ясап басалар. Һәрберсенең алдына берәр уенчык куела. Тәрбияченең «Таралыгыз!» дигән сигналы буенча, балалар үз урыннарыннан йөгереп китәләр һәм музыка астында ирекле рәвештә биеп, уйнап йөриләр. Шул арада тәрбияче уенчыкларның берсен алып куя, шулай итеп, уйнаучыларның берсен урынсыз калдыра. Ул бубенга нык итеп сугуга (яки «Урыннарыгызга!» дип кычкыруга), балалар нинди дә булса уенчык артына килеп басалар, уенчыкны, алып, югары күтәрәләр. Уенчыксыз калган бала «авыз ачып калучы» була. Уен 5–6 тапкыр кабатлана.

• Йөгерү һәм сикерү вакытларында тәрбияче бубен кагып торырга да мөмкин.

• Уен музыка белән оештырылса, музыка җитәкчесе уен барышын күзәтергә, билгеле бер этапларда музыканы җибәрергә яки туктатып торырга («Урыннарыгызга!» дип кычкырганда) тиеш була.

## Үз төсеңне эзлә

Балалар берничә төркемгә бүленеп басалар. Һәр төркемгә төсле тасмалар бирелә (бер төркемгә – кызыл, икенчесенә – зәңгәр, өченче төркемгә – яшел, сары ц. б.). Төркемнәр уртада капка калдырып, түгәрәк булып тезеләләр. Һәр төркемнең үз әйдәүчесе була. Аның кулында үз төркеменең тасмалары төсендәге флаг була. Балалар бубен тавышына яки музыка астында мәйданчык буенча таралып йөгерәләр. «Тукта!» дигән сигналны ишетү белән, алар тукталып калалар һәм күзләрен йомалар. Шул арада әйдәүчеләђр урыннарын алмашалар. «Үз төсеңне эзлә!» дигән сүзгә бөтенесе күзләрен ачалар һәм үз төсләрен эзләп йөгерәләр. Үзенең төсе янына беренче булып җыелып өлгергән төркем җиңүче була.

## Үз «капитаныңны» тап

Балалар, берничә төркемгә (командага) бүленеп, мәйданчыкның төрле урыннарында басып торалар. Һәр төркемдә бер бала «капитан» итеп билгеләнә. Төркемнәр үз капитаннарын уртада калдырып, кечкенә түгәрәкләр ясап тезеләләр. Төркемнәр музыка астында үз түгәрәкләре буйлап әйләнеп йөриләр һәм нинди дә булса эш эшләгән хәрәкәт ясыйлар (мәсәлән, язалар, чигү чигәләр, кер юалар һ. б.). Тәрбияченең «Йөгер!» дигән сүзенә барлык балалар мәйданчык буенча таралышып йөгерә башлыйлар, «Тукта!» дигәч, бар да тукталалар һәм күзлүрен йомалар. Шул арада капитаннар урыннарын алышыналар. Тәрбияченең «Капитаныңны эзлә!» дигән сүзләренә барысы да күзлүрен ачалар һәм ничек тә булса тизрәк үз капитаны янына җыелырга тырышалар. Үз капитаны тирәсенә башкалардан элегрәк җыелган төркем җиңгән санала. 2–3 уеннан соң капитаннар алмашына. Уен 4–5 тапкыр кабатлана.